# Малайларга, кызларга@.RU

### *2013 – Башкортстанда Тирә-як мохитне саклау елы*

Башкортстан Республикасы Президенты Рөстәм Хәмитов агымдагы елны Тирә-як мохитне саклау елы дип игълан иткән Указга кул куйды. Гүзәл табигате белән чит илләрнең данлыклы шифаханәләренә торышлы Башкортстаныбызның экологик иминлеген саклап калу һәм киләсе буыннарга тапшыру максатында ел дәвамында үткәреләчәк чаралар планы да расланылды.

Ел эмблемасын – зәңгәрле-яшелле тамчы фонында гәүдәләндерелгән ак бөркетне "Башкортстан" гәзите рәссамы, бизәлеш мөхәррире Нәсих Хәлисов иҗат иткән һәм ул махсус комиссия игълан иткән конкурска бирелгән эмблемалар арасында җиңүче дип табылган иде. Тирә-як мохитне саклау елы барышында экологик мәдәният, табигатебезгә сакчыл караш тәрбияләүгә, табигый мирасыбызны саклауга җаваплылыкны арттыруга юнәлтелгән чаралар үткәрелеп торачак.

Бу актуаль мәсьәләгә карата лицеебыз укучылары үз фикерләрен җиткерделәр

# *Сәнгатькә гашыйклар.*

Укучыларда җыр сәнгатенә карата кызыксыну тәрбияләүдә Лицеебызның талантлы укытучысы Акчурина Әлфия Фәнир кызының роле зур. Һәр укучының табигый талантын күрү, кызыксыну уяту, үстерү югары категорияле укытучының яраткан шөгыле. Укытучы аларны җыр сәнгатенең серләренә төшендерә, яңадан-яңа конкурсларда катнашырга дәрт һәм илһам бирә.

Шатлыклы нәтиҗәләргә игътибар итсәк, зур казанышлар күрербез. Архангель районында үткән "Язгы тамчы" конкурсында Линар Акчурин һәм Ильвина Хәкимова катнашып зур җиңүләр яуладылар, I һәм III дәрәҗәдәге лауреат исеменә лаек булдылар. Конкурсантлар республикабызның төрле районнарыннан (Уфа, Гафури, Архангель, Чишмә, Кырмыскалы, Авыргазы) килүен, анда катнашучылар санын исәпкә алганда да, минемчә, укучылар өчен дә, укытучы өчен дә бу — зур җиңү!



Район күләмендә үткәрелгән җыр ярышларында Әлфия Фәнир кызының тәрбиячеләре теләп катнаша. "Авыргазы йолдызчыгы" , "Люблю тебя, моя Отчизна!" конкурсларында җиңүнең иң югары баскычларын яуламый калмыйлар.

Шунысы игътибарга лаек, укытучы аерым җырчылар белән генә түгел, укучыларны хор (5 а, б) һәм ансамбльгә ("Элегия", 8в) оештыра белү осталыгын да күрсәтте. Гадәттә, сәләтле кеше бер генә өлкә белән чикләнми. Яшь җырчыларыбыз барлык фәннәрдән дә тырышып укыйлар, спорт белән дә шөгыльләнергә вакыт табалар. Ильвина Хәкимова, Айнур Бүләккулов безнең белән килешмичә калмас, мөгаен. Киләчәктә дә зур уңышлар сезгә!

Быел мәктәбебезгә яңа талантлы укучылар килде. Әлфия Фәнир кызы аларны шатланып каршы алды, музыка дәресләрендә тавышларын тагы да ныграк ачырга ярдәм итте. Сабина Зиннурова, Рина Бикколова әти-әниләр, укытучылар алдында чыгыш ясап, тамашачыларны таң калдырды. Мәктәптә килеп ике ай укуларына 1а, 1б, 1в сыйныф укытучылары Ягафарова Г.Н, Фәхретдинова Р.Ф., Нафикова Э.З. һәм укучылары зур эш башкарып, әти-әниләрне "Көзге уңыш" бәйрәмнәренә чакырды. Бу бәйрәмне музыкаль яктан бизәүче дә Әлфия Фәнир кызы булды.

Җыр сәнгатенә сөю Әлфия Фәнир кызының гаиләсендә дә зур урын алып тора. Әлфия Фәнир кызы – сөекле тормыш иптәше, уңган әни дә. Тормыш иптәше белән яңа йорт бетереп чыктылар, ул һәм кыз тәрбиялиләр. Бер-берсенә терәк булып, дус, тату яшиләр алар. Лицеебызда, районыбызда үткәрелгән һәр концертны дәртле җырлары белән бизәүче улы Линар бүгенге көндә Ишембай шәһәренең нефть колледжы студенты. Талантлы егетне инде анда да яратып тыңлыйлар. Кызлары Әдилә балалар бакчасына йөри, ул да үзенең матур тавышы белән тәрбиячеләрен, кечкенә тамашачыларын хәйран калдырган. Балаларга талант, һичшиксез, олылырдан бирелгән. Әлфия Фәнир кызының әнисе Бүләккулова Фәния Ялалетдин кызы республика "Озын көй" конкурсында Гран-при яулаучы, ә ул үзе Башкортстанда бик мәртәбәле "Туган тел" 2005 җыр конкурсы дипломанты!"Улым Линар белән дә, кызым Әдилә белән дә шөгыльләнү – тик шатлык кына",- ди талантлы балаларның әнисе.




Тырышлыгың, максатыңа омтылыш булмаса, уңышка ирешә алмыйсың. Без моны Әлфия Фәнир кызының бал кортыдай тырышып эшләвендә ачык күрәбез. Кечкенәдән җырга сәләтле балаларны музыка дөньясына алып керүдә иҗади уңышлар телибез сезгә!

## *Пөхтәлекне, чисталыкны һәрвакыт яратабыз*



Кирәк чакта җитез дә сез, тапкыр да сез,
Кирәк чакта сабыр да сез, батыр да сез,
Бик җаваплы, авыр сезнең хезмәтегез дә,
Тиешенчә күрсәгез иде хөрмәтен дә!

Кабинетларны җыештыру, ишегалдын тәртиптә тоту – тырыш апа - абыйларыбызның мактаулы вазыйфасы. Раушания Филәрит  кызы җитәкчелегендәге техник хезмәткәрләр барысы да мәктәп чисталыгы, матурлыгы өчен тырыша.

Һәр җирдәге пөхтәлек укытучыларның, укучыларның, мәктәп кунакларының  күңеленә рәхәтлек өсти. Пөхтәлек, чисталык, тәртип лицеебызны бик сөйкемле күрсәтә. Акыллы, сабыр холыклы, төгәл, чиста күңелле апалар һәм абыйларны хезмәттәшләре, мәктәпне тәмамлаучылар бүген дә аерым бер җылылык белән искә ала.

Армый-талмый хезмәт куючы, безнең күңелләребезгә яхшылык орлыклары сибүчеләр сез! Халыкның кәефе, күңел тынычлыгы күпчелек дәрәҗәдә сезгә бәйле.


Тырышлыгыгыз өчен зур рәхмәт! Җиңел булмаган хезмәтегездә уңышлар сезгә. Гади эшче хезмәтен бәяли белик!




# *Дөнья тынын тойган шагыйрь...*

(Рәшит Назаровның хәтеренә багышланган әдәби кичә)



22 ноябрь көнне мәктәп  китапханәсенэ табигать турында китаплар күргәзмәсен карарга бардык.Ул күргәзмәдэ  табигать турында шигырьләр, әкиятлэр сөйләнде.